ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» мая 2021 ел №128

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 сентябрендәге 297 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең яңа штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең «Производство зарурлыгына бәйле рәвештә яңа штат расписаниесенә үзгәреш кертү турында» 2021 елның 11 маендагы 254 номерлы үтенечнамәсен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең яңа штат расписаниесен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 сентябрендәге 297 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең яңа штат расписаниесенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Вазыйфаларны төшереп калдырырга:
«гардероб хезмәткәре» 2 штат берәмлеге санында;
«машина йөртүче» 0,5 штат берәмлеге санында.

1.2.Вазыйфаларны кертергә:
«касса хезмәткәре» 2 штат берәмлеге санында;
«хезмәтне саклау буенча белгеч» 0,5 штат берәмлеге санында.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**